КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 3 март г.Казань № б-439

Эчке һәм халыкара базарларда Татарстан Республикасы брендын һәм Татарстан предприятиеләре продукциясен алга таба этәрү, инвестиция һәм туристлык потенциалын арттыру һәм яшьләр белән һөнәри юнәлеш бирү эшен оештыру максатларында, шулай ук Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләү буенча оештыру мәсьәләләрен кичектергесез хәл итү өчен:

1. Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләү буенча ведомствоара эшче төркем составын;

Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясе блокларын эшләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген.

3. Әлеге ведомствоара эшче төркемгә Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләргә һәм аны 2022 елның 1 декабренә кадәр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

4. Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясе блокларын эшләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2022 елның 15 мартына кадәр әлеге блокларны эшләү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә.

5. Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләүне гомуми координацияләүне Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә.Кәримовка йөкләргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 3 март, б-439 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү стратегиясен эшләү буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, ведомствоара эшче төркем рәисе |
| Лернер Герман Янович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, ведомствоара эшче төркем урынбасары |
| Будкин Дмитрий Евгеньевич | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының төбәкара элемтәләрне үстерү бүлеге башлыгы, эшче төркем секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әйделдинов Айнур Тәүфыйк улы | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Идрисов Тимур Газинур улы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының төбәкара элемтәләрне үстерү бүлеге төп киңәшчесе |
| Казаков Юрий Михайлович | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры |
| Яковлев Альберт Валерьевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары. |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 3 март, 6-439 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының сәнәгать туризмын үстерү
стратегиясе блокларын эшләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы
дәүләт хакимияте башкарма органнары
исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 нче блок. Сәнәгать потенциалы һәм продукциянең сыйфаты | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 2 нче блок. Халыкны тоту һәм яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 3 нче блок. Туризм | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 4 нче блок. Инвест-потенциал | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицион-венчур фонды |
| 5 нче блок. Бизнес-алмашу (тәҗрибә һәм хезмәттәшлек) | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы |
| 6 нчы блок. Экологик аңбелем бирү | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 7 нче блок. Сәнәгать туризмы инфраструктурасын үстерү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы |

Икътисад министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы.